**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» март 2020 ел № 68

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын әзерләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, Азнакай муниципаль районы Уставының 7 статьясы нигезендә карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Тымытык авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын әзерләүгә керешергә.

2. 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын әзерләү буенча эшләр башкару вакытын билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары
Р. Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
№1 2020 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Тымытык авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын әзерләү буенча эш башкару срокларлары**

| № | Генераль план проектын әзерләү буенча эшләрне үткәрү тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Азнакай муниципаль районы "Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын әзерләү эшләрен оештыру | 2020 елның I-II кварталы |
| 2. | Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проектының беренче редакциясен әзерләү һәм килештерү | 2020 елның I-II кварталы |
| 3. | «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проектының ахыргы редакциясен әзерләү, фикер алышу һәм килештерү. | 2020 елның III-IV кварталы |
| 3.1. | «Тымытык авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын килештерү, бастырып чыгару. | |
| 3.2. | Ачык тыңлаулар үткәрү. | |
| 3.3. | "Тымытык авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын раслау. | |
| 3.4. | «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты нигезләмәләрен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясындагы 5,6 өлешләре нигезендә бастырып чыгару | |
| 3.5. | Азнакай муниципаль районының «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгына җибәрү | |